ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 351 от 17. 05. 2018 г.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре
арасында “Балаларны яклау көненә”
багышланган “Юниорлар, алга!”
XI район Спартакиадасын үткәрү турында

2018 елда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен физик культура белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы спорт коллективларын ачыклау максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. МКУ “Мәгариф бүлегенә” МУ“ Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” белән берлектә 2018 елның 31 маенда ( авыл зонасы) һәм 1 июнендә ( шәһәр зонасы) мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында “Балаларны яклау көненә” багышланган “Юниорлар, алга!” XI район Спартакиадасын үткәрергә.
2. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында “Балаларны яклау көненә” багышланган “Юниорлар, алга!” XI район Спартакиадасын үткәрү турындагы Нигезләмәне расларга (1 № лы кушымта).
3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында “Балаларны яклау көненә” багышланган “Юниорлар, алга!” XI район Спартакиадасы ярышларының территориаль зоналарын расларга (2 № лы кушымта).
4. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре арасында “Балаларны яклау көненә” багышланган “Юниорлар, алга!” XI район Спартакиадасының оештыру буенча комиссиянең составын расларга (3 № лы кушымта).
5. Призлы урыннар алган мәктәпкәчә учреждениеләрне түбәндәге тәртиптә акчалата премияләр белән бүләкләргә:

Шәһәр төркеме:
1 урын өчен-5000 сум;
2 урын өчен-4000 сум;
3 урын өчен-3000 сум;
кубоклар - 4000 сум;
программа төрләре буенча шәхси нәтиҗәләрне бүләкләү - 6000 сум.

Авыл төркеме:
1 урын өчен-4000 сум.
2 урын өчен-3000 сум.
3 урын өчен-2000 сум.
программа төрләре буенча шәхси нәтиҗәләрне бүләкләү-4000 сум.
Нәтиҗәдә: 40 000 сум (кырык мең сум).

6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Сергеев А.М.), Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ «Мәгариф бүлеге» сметасы буенча җирле бюджет акчалары хисабына 40 000 сум (кырык мең) күләмендә акчаларның җиңүчеләрне бүләкләү һәм ярышларны үткәрү максатында үз вакытында бүленүен тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов